| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с. Тюлячи **КАРАР**

«20» декабрь 2018 № 846

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 31, 32, 33 статьялары нигезендә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, үзара хезмәттәшлек кысаларында һәм Теләче муниципаль районы прокуратурасы тарафыннан Теләче муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында 2018 елның 29 сентябрендә кабул ителгән күрсәтмәләрне үтәү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерли башларга.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия төз.

3. Расларга:

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә № 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча комиссия составын

- Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә № 2 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча комиссия турында нигезләмәне.

4. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырырга.

Җитәкче И.Х.Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның “__”_____ №__
карарына кушымта № 1

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Валеев Ф.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы. |

Комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Галәвиев И.И. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Сөнгатуллин Н.М. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе; |
| Емельянов Ю.И. | - | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы; |
| Сөнгатуллин Р.Р. | - | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» РДУП Теләче участогы начальнигы (килешү буенча); |
| Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары | - | карала торган җир биләмәләреннән файдалану һәм авыл җирлеген төзү кагыйдәләре буенча территориаль ведомствога карап. |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның “__”_____ №__
карарына кушымта № 1

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча комиссия турында Положение**

## 1. Гомуми положениеләр

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү буенча комиссия (алда - Комиссия) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре территориясендә җирдән файдалану һәм йортлар салу системасын камилләштерү һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен оештырыла.

2. Комиссия Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән оеша.

3. Комиссия даими эшли һәм үз эшчәнлеген Россия Федерациясенең Шәһәр төзү кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45 санлы Татарстан Республикасы Законына һәм әлеге Положениегә нигезләнеп башкара.

## 2. Комиссия составы

1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

2. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын рәис урынбасары башкара.

## 3. Комиссиянең компетенциясе

1. Комиссиянең компетенциясенә керә:

1.1. Җирдән файдалану һәм йортлар салуны көйләү системасын эзлекле формалаштыру һәм камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм йортлар салу Кагыйдәләренә һәм шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертү, ә киләчәктә аларны тормышка ашыру.

1.2. Гражданнарның һәм юридик затларның җирдән файдалану һәм йортлар төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү белән бәйле тәкъдимнәрен карау.

1.3. Җирдән файдалану һәм йортлар төзү кагыйдәләренә һәм шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертү буенча халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү.

1.4. Халык тыңлаулары буенча нәтиҗәләр ясап, тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китереп, район башкарма комитеты җитәкчесенә җиткерү.

## 4. Комиссия эшчәнлегенең тәртибе

1. Комиссия гариза кергәннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча җыела.

2. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының билгеләнгән санының өчтән ике өлешеннән дә ким булмаган катнашучы булганда гына ул тулы хокуклы санала.

3. Комиссия карары утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының күпчелегенең тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала. Комиссия карары тәкъдим буларак кабул ителә.

4. Комиссия эшчәнлегенең техник тәэминаты Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләнә.

5. Комиссия җирдән файдалану һәм йортлар төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында тәкъдим кергәннән соң 30 көн эчендә үзгәрешләр кертү яки бу тәкъдимне кире кагу (кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп) турында нәтиҗә әзерли һәм тиешле карар кабул итәр өчен аны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрә:

- җирдән файдалану һәм йортлар төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча материалларны халык тыңлавына куярга;

- җирдән файдалану һәм йортлар төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында кергән гаризаны кире кагарга.